ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН МӨСТӘКЫЙЛЬ ҺӘМ КОНТРОЛЬ ЭШЛӘР ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

Казан
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциясендә

Редактор:
Р.Р Шәмсетдинова, Өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф оешмасы“Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филол. ф. канд., доцент

Төзүче- авторлар:
Р.Р Шәмсетдинова, өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф оешмасы “Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филол. ф. канд., доцент
Л.Г. Гыйләҗева, өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф оешмасы “Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филол. ф. канд.
Р.Ф. Фәттахова, өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф оешмасы “Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филол. ф. канд.
Г.В.Хадиева, өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф оешмасы “Татарстан республикасы Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филол. ф. канд.

Гомуми белем бирү мәктәпләренең 9, 11 сыйныф укучыларының белемнәрен тикшерү,контроль эшләр үткәрү өчен диктант һәм изложение текстлары. Җыентыкта язма эшләрне бәяләүнең критерийлары да китерелә. Текстларны бердәм республика имтиханнарына әзерләүөчен дә файдаланырга мөмкин.

© ТРМҮИ, 2017

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

### Язма эшләрне бәяләү критерияләре

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була.

*Уку елы ахырында имтихан буларак үткәрелә торган (Дәүләт йомгаклау аттестациясе – ГИА-9, ГИА-11) язма эшләрне (безнең очракта диктант, изложениене) бәяләү түбәндәгеләрдән чыгып башкарыла.*

Укучы диктант текстында өйрәнелгән темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны яхшы белергә, хаталар ясамаска тиеш. Контроль диктантта төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә.

**Диктантны бәяләү**

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса “5” ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә “4”ле куела.

4 орфографик, 4 пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пунктуацион хаталы эшкә “3”ле куела.

6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунктуацион хаталы эшкә “2”ле куела.

### Изложениене бәяләү

Изложениене бәяләгәндә, фикернең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләмнең камиллегенә, грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә. Изложение өчен ике билге куела: беренчесе – эчтәлек һәм сөйләмне дөрес оештыра алуга, икенчесе – грамоталылыкка.

Тема тулысынча ачылган, эчтәлеге һәм стиль берәмлеге сакланган эшкә “5” ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булырга мөмкин).

Текстның эчтәлеге темага, нигездә, туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлар җибәрелсә, 1-2 фактик, 1-2 техник хатасы булса, 2 орфографик, 2-3 пунктуацион, 1 грамматик хатасы булган эшкә “4” ле куела.

Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, 3 фактик, 2-3 техник хатасы булса, 3 орфографик, 4 пунктуацион, 2 грамматик хатасы булган эшкә “3”ле куела.

Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталар күп булса (5 тән артып китсә), орфографик хаталарның саны 4 тән артса, пунктуацион хаталарның саны 5 тән, грамматик хаталар саны 3 тән артса, “2” ле куела.

## IX СЫЙНЫФ

## ДИКТАНТ ЯЗДЫРУ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

### Канатлы дусларыбызны онытмыйк

Менә ак тунлы кыш та килеп җитте. Бер-ике көн эчендә әллә никадәр кар яуды . Бөтен тирә-як ак юрган астында калган кебек иде. Кыш җитүгә, урманда кошларга азык табу шактый кыенлашты.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр ясап куярга һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәтергә кушты. Без моңа шатланып риза булдык. Мәктәптән кайткач, һәрберебез җимлек ясарга керештек.

Мин дә тактадан кечкенә генә өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман янындагы карт чыршы төбенә куйдым. Чыршының куе ботаклары җимлектәге азыкны кар басудан сакларлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли, шуңа күрә без урман эчендәге өйдә яшибез.

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, кипкән миләшләр салдым. Бер читтән генә карап тора башладым. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар да агач ботагына кундылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Минем җимлегемдә алар өчен дә сый бар иде: аларга мин миләш асып куйган идем, рәхәтләнеп миләш чукыдалар канатлы дусларым. Миләш чыпчыгы да авыз итте минем җимлектәге азыктан. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән китәргә ашыкмыйлар да әле. Кинәт җимлек өстендәге ботакка тиен сикереп менде. Ул да җимлектә рәхәтләнеп сыйланды.

Хәзер мин көн саен канатлы дусларыма җим бирәм. Кошлар да, тиеннәр дә рәхим итсеннәр. (200 сүз)

(*Ш.Бикколдан*)

### Кыш көне тауда

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Үзем генә барам. Дусларымны көтеп, тау шуарга баруны сузасым килмәде. Мин, гомумән, табигатькә ялгызым чыгарга, ялгызым йөрергә яратам. Әнкәй елмаеп тәрәзәдән карап калды. Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә төртеп үк, миңа карап калды.

Мин еракка китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-нә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы. Тирә-якта кар ап-ак, тирән. Ак кар өстендә бик күп эзләр бар. Менә монда төлке, бүре эзләре. Эзләренә караганда пошилар да азык эзләп авыл янына килгәннәр. Ә куян эзләре исәпсез-хисапсыз. Кар өстендәге эзләр буенча хикәя язарга мөмкин икән бит. Бүген көн салкын. Җил дә юк. Бөтен җир ап-ак! Өченче көн инде шулай. Мондый көннәрне мин санап барам. Кинәт җайлап

кына кар ява башлады. Кар яуса, көн җылыта, дигән иде әти. Җылытыр, ахрысы.

Монда җәй көне нинди җылы иде! Чәчәкләр бар иде. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр... Күбәләкләр!Мин ак күбәләкләрне яратам. Кар бөртеге, ак булса да, күбәләк була алмый. Кыш көне күбәләк кар була, боз була...

Салкын булуга карамастан, минем кулларым өшеми. Чөнки минем җылы бияләйләрем бар. Бик җылылар, җылы булмаска, аларны миңа әнием бәйләде бит.

Кара-кара! Кар бөртекләре ничек күп булып ява башлады!.. Әнә нинди эзләр күмелә! Бүре эзләредер әле, күмелсеннәр тизрәк. Алар мине бераз куркыта. Куян эзләреннән мин курыкмыйм. Тик куян эзләре күмелеп тә бетте шул инде... Кар һаман ява. Моннан безнең өебез күренеп тора. Әткәй эштә инде. Әнкәй әле һаман тәрәзәдән карый микән? Гайнулла бабай да карыйдыр. Алар мине күрә микән? Хәзер мин үзем тапкан тауга менәм. Яңа карга яңа эз салам. ( 212 сүз) (Р. Фәиздән)

**Шомырт нигә елый**

Зәй буендагы ул ялгыз шомырт төбендә бер җәйне бик күнелле ял иткән идек без. Шул көннән бирле шомырт якын дустыбызга әйләнде һәм без улым белән һәр язны шомыртыбызның хәлен белергә бара торган булдык. Шомырт безне бик куанып каршылый, бөреләрен яңа гына ачып чыккан нәни-нәни яфраклы кул-ботакларын изәп, безне сәламли. Аннары без шомыртыбыз янына шау чәчәккә төренер чагында киләбез. Җәй азакларына таба да без шомыртыбызга кунакка киләбез. Дустыбыз безне тәмле кара җимешләре белән сыйлый.

Быел шомыртыбызның яфрак ярган шатлыгын уртаклашырга, ничектер, бара алмый калдык. Шунлыктан аның мул чәчәкле, хуш исле бәйрәменә вакытында барып җитәргә ашыктык.

Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, шомыртның бик моңаеп, боегып утырганын күрдек. Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы икәнни?

Килеп җитүгә, дустыбыз каршында башларыбызны иеп, сүзсез басып калдык. Юк, чәчәкләрен коймаган шомырт, аны талаганнар. Ботагы-ботагы белән сындырып алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр. Ул каерылган канат-ботак җиргә үк салынып төшкән, яфраклары, әрнеп, йөзләрен җыерганнар. Тал-тирәк арасында ниндидер кошлар моңсу гына сайрашып куя, бөтен Зәй буе моңсуланып, шыксызлынып калган иде. Акрын гына шомыртыбыз янына атладык.

— Шомырт... елый, – диде улым, агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчыларга карап, үзенең дә күзләреннән мөлдерәп чыккан күз яшьләрен кул аркасы белән сөрткәләп алды.

Әйе, елый иде шомырт... (203 сүз)

( Р. Төхвәтуллиннан)

## Равил гаебен таныды

Равил, мәктәптән кайткач,ашады, эчте дә, тимераякларын алып, урамга чыгып китте.Ул кузгалып китәргә торган автобус артына тотынып барырга теләде. Автобус кузгалды. Алдагы тукталышка җитәр алдыннан, Равил кулларын ычкындырды һәм юлның икенче ягына чыкты. Ләкин каршыга килә торган йөк машинасын ул күрмәде.

Кинәт кенә машина алдына килеп чыккан баланы күргәч, тәҗрибәле шофёр да каушады.Зур тизлек белән килгән машинаны туктатырга соң иде. Шофёр гәүдәсе белән рульгә ятты һәм машинаны тротуарга борды. Машина баганага бәрелде һәм туктап калды.Ә Равил алдына-артына карамыйча йөгерде.

Икенче көнне Равилнең күңеле тыныч, кәефе яхшы иде. Кичә булган хәлне ул исенә дә төшермәде. Әйтерсең, бернәрсә дә булмаган!

Зур тәнәфес вакытында Равил коридорда сыйныфташлары янына килде. “Хәзер әтине эшеннән чыгаралар”, - диде Сәлим, күңелсез генә. “Нәрсә булды? Ни өчен?” – дип сорады Равил. Аңа кичәге вакыйганы сөйләп бирделәр.

Равил бик борчылды, аның Сәлимнең әтисенә ярдәм итәсе килде. Иртән торгач, ул Сәлимнең әтисе эшли торган җиргә барды. Директор кабинетына керде, аның белән исәнләште дә: “Барый абый Сөләймановны эшеннән чыгармагыз, директор абый. Ул гаепле түгел!” – диде. “Ничек гаепле түгел? Ул бит машинаны ватты!” – диде директор. “Минем аркада ул,” – диде Равил һәм барысын да сөйләде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Директор Сөләймановны чакыртты, машинага ремонт ясарга кушты. Сәлимнең әтисе эшендә калды. (204 сүз)

(Ә.Дибаевтан)

## Талантлы композитор – Салих Сәйдәшев

Татар музыка сәнгатенең иң күренекле вәкиле, татар профессиональ музыкасына нигез салучы талантлы композиторыбыз Салих Сәйдәшев 1900 елның 3 декабрендә Казанда туа. Әтисе улы туарга 15 көн кала дөнья куя. Әнисе Мәхүпҗамал апа шәфкатьле, ярдәмчел, хөрмәтле кеше була.

Салихның тормышында якты, тирән эз калдырган, композиторның беренче терәге, зур ярдәм күрсәткән кеше – җизнәсе Шиһап Әхмәров була.

Әминә апасы белән тормыш коргач, җизнәсе аны үзенә тәрбиягә ала. Аның музыка белән кызыксынуын күреп, Салихның сәләтен үстерү өчен, уңайлы шартлар тудыра, бар көчен куя.

Сәйдәш музыкасының әһәмияте, кыйммәте көннән-көн, елдан-ел арта бара. Ул халыкка 400 дән артык җыр, романс, увертюралар, маршлар бүләк итә. Шул исәптән, 40 ка якын сәхнә әсәренә музыка яза.

Музыкасы белән генә түгел, шәхес буларак та Сәйдәшев халык арасында ифрат популяр кеше булган. Кешеләр белән ул бик теләп аралашкан, мохтаҗларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торган. Зур популярлыгына карамастан, иптәшләре арасында үзен гаҗәп дәрәҗәдә тыйнак тоткан.

Замандашлары күңелендә ул урта буйлы, очкын чәчеп торган зәңгәр күзле, гаҗәеп ягымлы, җитез, йомшак табигатьле кеше булып сакланган.

Әдәбиятта без иң беренче Тукай дисәк, музыкада иң беренче Сәйдәш исемен әйтәбез.

Сәйдәш моңнары... Бу сүзләрдә никадәр тирән мәгънә, туган җиргә, туган якка булган никадәр мәхәббәт, никадәр тылсымлы, серле көч ята. Татар музыка сәнгатен үстерүдә Салих Сәйдәшевнең өлеше чиксез зур. (200 сүз)

(Вакытлы матбугаттан)

## Мин кулыма китап алам

Без – китаплы халык. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән кульязма китаплар шул хакта сөйли. Кульязмаларны күчереп язучы осталар барлыкка килгән. Халык арасында шуңа күрә кулдан язылган китаплар күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр галимнәр кульязма китапларны табып торалар.

Аннан басма китаплар чоры башланган. Хәтта Италиядә дә Шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралган. Ләкин алар гарәп һәм фарсы телләрендә булган. Безнең әби-бабайларыбыз үз телләрендә белем алганнар, шул ук вакытта фарсыча да, гарәпчә дә белгәннәр, шуңа күрә ул китапларны укый алганнар. Шунысы мөһим: без үзебез генә белемле булып калмаганбыз, мәгърифәт нурларын башка тугандаш халыкларга да таратканбыз.

Яңа чорлар килде. Радио-телевидение, компьютер, интернет заманы. Техника, электроника үзгәрә, компьютерлар, телефоннар, телевизорлар яңара, камилләшә. Уены да шунда, дәреслекләре дә, фильмнары да, музыкасы да, фотосурәте дә – барысы да... Фәнни-техник прогресс, һичшиксез, уңай күренеш.

Тик классикларыбызны укып үсмәгән, бүгенге язучыларыбызны белмәгән милләтттәшләребез рухи тамырларыбызны да, тарихыбызны да, гореф-гадәтләребезне дә аңламаслар дигән шигем бар.

Без күп гасырлар дәвамында белемне бары тик китап аша алганбыз. Дөнья цивилизациясенең казанышларын да, халкыбызның бай тарихын да, рух ныклыгын да безгә китап биргән. Шуңа күрә дә без Китапка чиксез рәхмәтле.

Бүгенге көндә безнең төп рухи таянычыбыз китап булырга тиеш! Китапсыз күңел – буш күңел, китапсыз йорт – нурсыз йорт, китапсыз милләт – киләчәксез милләт. Бәхетебезгә, без андыйлар түгел! Әлегә... (199 сүз)

(Р.Миңнуллин буенча)

## Рәмзиянең әбисе

Рәмзия әбисенә чәй әзерләргә булышты. Ак чәйнектән чынаякларга чәй агызгач, өйгә тәмле ис таралды. Шушы эшләр арасында Рәмзия әбисенең яшь чагын күз алдына китерергә тырышты. Ләкин ул аны берничек тә яшь, таза, җитез итеп күз алдына китерә алмады. Ул һаман шулай кечкенә, ябык, гап-гади бер карчык булгандыр кебек иде.

— Әби, синең яшь чактагы рәсемең юкмы? – диде ул, әбисенең яшь чагын күрәсе килеп.

— Бар, ник булмасын, – диде карчык. Карчык комод тартмасын ачты да төргәктән зур гына бер рәсемне алып, оныгына күрсәтте.

— Әбиеңне табасыңмы менә шуннан? – диде.

Рәсемдә бер төркем хатын-кызлар иде. Күбесе – яшьләр. Өчпочмаклы яулык бәйләгәннәр. Яулыксызлары да бар. Рәмзиягә әбисе моннан 50 еллар элек булган очрашу турында сөйләде, хәтта рәсемне ни өчен эзләп табуын да онытты.

— Әбием, син бит әле үзеңне күрсәтмәдең, – дигәч кенә, бер ябь-яшь кызга күрсәтте.

Ачык якалы блузка кигән, билен каеш белән буып, иңбашыннан нәзек каеш җибәргән, кыска чәчле, түгәрәк ягымлы йөзле, зур кара күзле кызны ул, үзенең әбисе дип, беркайчан да әйтә алмас иде.

Ул көнне Рәмзиягә әбисе бик күп истәлекләр сөйләде. Алар мактау кәгазьләрен карадылар, саклангаң хатларны укыдылар. Аларда әбисенең яшьлеге генә түгел, аңа таныш булмаган бөтенләй яңа бер тормышның истәлекләре икәнен аңлады ул. Аның әбисе, Һәҗәр карчык, бу тормышта бик кирәкле, бик кадерле кеше булган икән бит. (200 сүз)

(Л. Ихсановадан)

### Күңел күзе

Ландышлар чәчәк аткан вакытта, Камил әтисе белән урманга барды. Әтисе юлда аңа: “Урман ул– зур, серле, күңел күзе белән карасаң гына, бөтен нәрсәне күрерсең”, диде. Камил көлеп җибәрде: “Кешенең күзе маңгаенда гына була, күңелнең күзе булмый, шаяртасың”, - диде. Әтисе каршы килмәде. “Шулай, тик күңел күзе белән карамасаң, маңгай күзе берни күрми ул. Шуңа күрә борынгылар, маңгай күзе – ботак тишеге, дигәннәр”, - диде.

Урман аларны тын гына каршылады. Биек-биек наратлар селкенми дә утыралар. Камил өскә карады. Агач башлары сизелер-сизелмәс кенә селкенәләр, әйтерсең үзара нәрсә турындадыр сөйләшәләр.

Шулчак бер нәни кошчык, Камилләр янындагы ботакка кунып, ярсып чыркылдарга тотынды. Камил белән әтисе, тын да алмыйча, кошны күзәттеләр. Ачулы кош аскы ботакка төшеп кунды һәм тагын да усалрак итеп чыркылдарга тотынды. Камилнең әтисе көлемсерәп куйды:

— Бу кош безгә моннан китәргә куша бит әле, ачулана. Бәлки, бу агачта аның оясы бардыр...

Камил, ашыгып, әтисенең сүзен бүлде:

— Оясында балалары бардыр. Әнә әти кош балаларына җим алып кайткан.

Камилләр башка агач төбенә күчеп утырдылар. Кошларга шул гына кирәк иде дә, шунда ук тынычландылар. Камил аларның ояларын күрергә теләп

караса да күрә алмады. Кайтыр юлга чыккач, моны ул әтисенә әйтте. Әтисе аны юатты, аркасыннан сөйде.

— Аның каравы, урманны күңел күзе белән карарга өйрәндең. Ә кош оясын күрергә кирәкми дә, – диде. (200 сүз)

(Р.Хафизовадан)

**Язмышлар**

Без кем һәм кайдан? Нинди язмышлар йөртә безне читләрдә?

Әтине бала чагында, 1917 нче елгы Октябрь революциясеннән соң берничә ел үткәч, әнисе һәм үзеннән кечерәк өч сеңлесе белән ерак Кытайга алып китәләр. Алар чыгышлары белән Пенза өлкәсенең Нопар авылыннан. Туган яклардан аерылу ачысы, авыр һәм михнәтле юллар, катлаулы, озакка сузылган сәяхәт. Мәрхүм әбиемнең батырлыгын, тәвәккәллеген ничек аңлатырсың да, аңа ничек сокланмассың? Үзенең туган теле булган татар теленнән башка тел белмәгән авыл хатыны, берсеннән-берсе кечкенә дүрт сабый баласын алып, меңнәрчә чакырымлык юлга чыга. Бар байлыгы бер чемоданга сыеп беткән аның, ләкин самовары булган. Алар Благовещенск каласыннан Кытайга үтәләр. Яңа тормыш кору кайда да җиңел булмый, билгеле. Әмма татарга хас тырышлык ярдәм итә аларга. Җиң сызганып эшлиләр, җиңелме – авырмы дип тормыйлар. Татарлар берләшә башлый. Үзләренә җәмгыять төзергә, мәчет салырга, мәктәп ачарга ниятлиләр. Һәркем кулыннан килгән кадәр ярдәм итә. Шулай итеп, татар мәдәниятенең һәм ислам учагының нигезләре салына башлый Кытайда.

Әнием дә шул ук Пенза якларыннан. Революция дәһшәте, гражданнар сугышы аның гаиләсен дә туздыра. Әниемне абыйсы Харбин якларына җибәрә. Менә шулай язмыш әтием белән әниемне ерак Кытайда кавыштыра. Алар гаилә корып җибәрәләр, бик матур, күпләргә үрнәк булырык итеп яшиләр алар. Ләкин 1945 нче елда әтиемне бер гаепсезгә кулга алалар һәм әнием, өч баласын алып, мең бәла белән Төркиягә китеп урнаша. Аңа анда да тормышны өр-яңадан башлап җибәрергә кирәк була. Әтием безнең янга егерме елдан соң гына кайтты.

Әйе, язмыш катлаулы, ә без – язмыш балалары. (200 сүз)

(Ф. Иделледән)

**Институттан куылу**

Ул көнне, социаль чыгышы шикле затның баласы буларак, институттан куылып кайтып кергәндә, әни өйдә иде. Дәфтәр тикшереп утыра. Ул - укытучы. 18 нче татар мәктәбендә башлангыч класс балаларын укыта. Үзе дә, читтән торып, педагогия институтында укый. Күрәсең, минем хәсрәтем йөземә бәреп чыккан булгандыр, әнием, шунда ук эшеннән аерылып, сорау белән миңа текәлде. Бер мизгел тынлык булып торды. Әнием тиз генә үзен кулга алды,

мөмкин кадәр тыныч тавыш белән: “Кайгырма, улым, бирешмә, балакаем”, - диде.

Кадерлем, бәгырем минем, бердәнберем, газиз әнием! Сине табигатең ничек шулай көчле яратты икән? Бу минутта, бәлки, башка ана булса, еларга яки мескенләнергә керешер иде. Ләкин минем әнием андыйлардан түгел.

Тормыш ифрат авыр. Әниемнең эш хакы аз. Икмәк карточка белән генә бирелә. Ашаган төп ризык - бәрәңге.

Без Вахитов заводы янында бер фатирда яшәгәндә, әниемнең аягына брезент итек киеп кыш уздырганын яхшы хәтерлим. Аның кышкы суыкларда мәктәбеннән кайткач, сызланып, тезләрен уып, мич авызы каршында утырган чакларын онытасым юк.

Кыскасы, безнең эшләр бик үк мактанырлык түгел иде. Ләкин шуңа да карамастан без, әниле-уллы, үзебезне моңарчы бик бәхетле сизеп яши идек. Ник без бәхетсез булыйк: тормыш – илдәгечә, без һаман үсәбез, укыйбыз, куйган максатыбызга барабыз. Тик бу бәхет бүген, боздан ясалган бинадай җимерелде. Хәзер инде эшкә урнашу турында уйларга кирәк. (202 сүз)

(А.Расих буенча)

## ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗДЫРУ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

### Сугыш башлану

Мөнирә, йөзен куллары белән каплап, сугыш башланган сәгатьләрдә кайда булганын, нәрсә эшләргә әзерләнгәнен исенә төшерергә тырышканда, аның күз алдына Казанның күләгәле борынгы бакчасы килеп баса торган иде. Җәйге аяз көн. Шәһәрнең бөтен яшьләре паркка, спорт бәйрәменә җыелганнар. Медицина институты студентлары арасында Мөнирә белән Таня да бар. Һәҗәр химия-технология институты студентлары арасында. Театр училищесы студентлары уртасында Ләләнең тавышы ишетелә. Надя – педагогия институты, Хафиз университет командасы белән килгәннәр.

Сәгать унбердә кроссны башлап җибәрделәр. Менә кызлар биш йөз метрга йөгерә башладылар. Надя Егорова башта ук иң алга чыкты. Надя артыннан ун-унбер адымнар гына артта калып, кыска аксыл чәчле бер кыз килә. Аның артыннан ук Таня һәм Мөнирә. Финиш янында гына аларны Ләлә куып җитте.

Бакча өстендә, яшел яфраклар шаулавына талгын музыка тавышы кушыла. Кызларның йөзләре көләч, аларны һични куркытмый. Киләчәк аларга шушы июнь күге кебек саф, болытсыз, матур булып күренә. Ләкин нидер булды. Музыка кинәт туктады, халык, ашыгып, парк үзәгендә урнаштырылган репродукторларга таба авыша башлады.

Радиодан иптәш Молотов сөйли иде. Кызлар аның сөйләвенең башын ишетмәделәр. Шуңа күрә башта сүзнең нәрсә турында булуын аңламадылар. Аннары барысы да аңлашылды – сугыш башланган. (178 сүз)

Г. Әпсәләмов буенча

## КИТАП

Китап... Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь. Бары шул гына, ә яхшылап уйлап карасаң, китап ул – адәм баласы уйлап чыгара алган могҗизаларның могҗизасы.

Могҗиза, чөнки Пушкин үлгән, Тукай үлгән, Гоголь, Толстой юк, ә без алар белән кара-каршы сөйләшкән кебек сөйләшәбез, алар нинди уйлар белән яшәгәннәр, язып калдырган китапларының битләрен ачып, без дә шул уйлар белән янабыз... Моннан ничә мең еллар элек яшәгән борынгы Мисыр, Рим, Һинд язучылары, галимнәре бүген безнең белән янәшә яшиләр, китаплары безнең алдыбызда. Без китап битендә борынгы Мисыр кызының матур елмаюын күрәбез.

Дәүләтләр яшәгән – беткән, халыклар яшәгән – сөяге дә калмаган. Ай калган, Кояш калган да китап калган... Таш китап, үлән китап, тире китап, ефәк китап, кәгазь китап калган...

Әйе, гомере буена Китап – кешенең аерылгысыз юлдашы. Ул халыклар белән халыкларны таныштыра, буыннар белән буыннарны кавыштыра.

Беренче китап XI йөздә Кытайда басылып чыга. 1445 нче елдан башлап бөтен Европага тарала. Татар телендә басылган беренче китап гарәп хәрефләре белән 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә чыга.

Италиядә Шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралган булган. Ләкин алар гарәп һәм фарсы телләрендә. Халык арасында шуңа күрә кулдан язылган китаплар күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр галимнәр кулъязма китапларны таба торалар. (180 сүз)

*Ибраһим Газидән*

## КЕРПЕ

Керпе – бик кызыклы хайван. Аны ялан кул белән тоту мөмкин түгел, чөнки ул шунда ук чәнечкеле йомгакка әйләнә. Ә үзе кулга тиз ияләшә, йомарланмый башлый, маңгаендагы кыска йоннары астыннан кызыксынучан күзләре белән карап, ялтыравык төймәгә охшаган озын борынын чыгара, сөт һәм башка ризыктан авыз итә. Керпе җиләк, үлән, бака ашый.

Керпе кышны тирән йокыда үткәрә, азык запасы әзерләми. Көзен үзенә кечкенә чокыр казый, аның төбенә коры яфраклар түши. Кышкы салкыннар җиткәч, шул ятагына кереп чума. Апрель ахырында - май башында кышкы йокысыннан уяна.

Керпе баласы чукрак, сукыр, ялангач һәм энәсез булып туа. Туып берничә сәгать үтүгә, тәненә йомшак энәләр үсә башлый. Бераздан ул энәләр ныгый, катылана, аларда ак буйлар барлыкка килә. Әниләре бала керпеләрне йомгакланып төрелергә һәм сүтелергә өйрәтә. Соңрак ул аларны ризык эзләргә алып чыга. Бөҗәкләр, коңгызлар эзләргә өйрәтә. Гөмбәләр белән таныштыра. Бала керпеләр әниләре биргән дәрестән яшәү күнегүләре алалар.

Керпеләр алма һәм башка предметларны энәләренә чәнчеп ташыйлар, моның белән алар тәннәрендәге паразитларны бетерәләр. Ничек итеп дисезме? Алманың әче суы керпенең тиресенә агып төшә һәм андагы паразитларны куркыта. Менә шулай итеп, керпеләр тирәлеккә җайлашалар (176 сүз)

М. Рафиковтан

**Туган авылым**

Мин үземнең илемне, туган ягымны бик яратам. Ак карлы кышының да, алтын көзенең дә, чәчәкле җәенең дә кабатланмас матурлыгы бар безнең якларның. Тик шулай да мин язларга гашыйк.

Баш очында гына тургай талпына. Аның җыры зәңгәр һавада яңгырап тора да язгы кояш нурларында изрәп яткан кыр өстенә коела. Гөрләвекләр тавышына кушылып, сине хискә күмә, моңа чаклы йоклап яткан күңел кылларыңны тибрәтеп җибәрә.

Майның урталары. Авылның иң матур вакыты: көннәр җылы, ямьле, һава саф, йомшак, авылны урап алган кырларда төрле ашлыклар ямь-яшел булып үсәләр. Күкне тутырып тургайлар сайрый. Кырларны әйләндереп алган урманнардагы төрле агачлар куе, яшел яфракларга, чәчәкләргә күмелгән. Анда мең төрле кош сайрый: сандугачлар, күкеләр, тургайлар һәм башкалар.

Урманнарның аланнары төрле-төрле матур чәчәкләр белән бизәкләнгән. Ул чәчәкләр куе үләннең карасу кыяклары эченнән, күктәге йолдызлар кебек күзгә карап, көлеп, елмаеп торалар. Куе агачлар эченнән вак ташлыклардан көмеш кебек сулы салкын чишмәләр мөлдерәп һәм чылтырап агалар. Авыл аркылы чыккан тирән генә, тар гына саф сулы инеш ямь-яшел болынны икегә аерып китә. Ул инештә, тәнгә сихәт бирә торган суыннан чыкмыйча, балалар, үрдәкләр, казлар җәй буе коеналар. Матур да соң безнең авыл! (177 сүз)

М. Хәбибуллиннан

**Маһия әби**

Автобус тигез юлдан, тузан туздырып, алга чаба. Кинәт юл читендә чандыр гына бер карчык күренде. Ул кәшимир яулык бәйләгән, ә өстендә кызыл бәрхеттән тегелгән камзул белән бала итәкле күлмәк, аягында бизәкле читек-кәвеш иде. Менә ул таягын өскә күтәрде. Шофёр егет автобусны шунда ук туктатты. Әби, рәхмәт укый-укый, минем яндагы буш урынга килеп утырды. Итәкләрен рәтләп, як-ягына каранып алды.

Әби сүзгә бик оста булып чыкты. Пассажирлар белән бик тиз элемтәгә керде. Арткы урында утырып барган чуваш агае белән чатнатып чувашча сөйләшә башлады, икенче берәүнең русча биргән соравына да шома гына русча җавап кайтарды. Мин түзмәдем, сорап куйдым:

— Әби, син ничә тел беләсең соң?

— Ничә тел дип инде, балам... – Маһи әби, яулыгын төзәткәли-төзәткәли, бармакларын бөгеп санап китте:

— Татарча – монысын үз телем булганга, чувашча – күршеләр теле, русча белмәү гөнаһ инде, балам. Шуларга кушып, гарәпчә дә укыштырам. Әле Казахстан якларыннан кайтам. Сеңлем яши анда. Шунда казахлар белән дә рәхәтләнеп аралаштым. Тел бик кадерле нәрсә, телләр белү зур хәзинә ул, балам. Юкка гына халык: "Телләр белгән – дөнья гизгән," – димәгән. Тик кешеләр шул тел белән бер-берсен рәнҗетеп кенә ялгышалар. (176 сүз)

(Г.Сабитовтан)

**Ярдәм**

Көз килде. Бакчадагы агачлар яфракларын коеп бетерде диярлек. Агачта калганнары исә аз гына кагылуга, җиргә сибеләләр. Кошлар да җылы якларга киткәннәр. Бары песнәкләр, чыпчыклар һәм ала каргалар гына калган.Алар кышын курыкмыйлар бит. Өч көн яңгыр яуды һәм суытып җибәрде. Аяк асты – көзге шикелле, боз. Сакланып басмасаң, егылырга бик мөмкин. Малайларга шул гына кирәк, алар чаналарын алып тауга киттеләр.

Таудан бер бабай төшеп килә. Бер кулына зур кәрзин тоткан. Икенче кулында – таяк. Бабай бер атлый да туктый, тагын атлый да туктый. "Ничек төшәр икән инде бу бабай? Кәрзине дә авыр ахры," – дип уйлады чана шуучы малай һәм бабай янына килде. Янында чанасы да бар иде. Малай карт янына килеп басты да аның кәрзинен алды: "Бабай, кәрзинегезне бирегез, аска алып төшәм, аннары үзегезне дә алырга менәрмен", – диде. Бабай аңа: " Ай акыллым! Кәрзинем төшсә, бик яхшы. Кәрзин булмагач, үзем әкрен генә төшәрмен әле!" – диде. Малай аңа:"Чанам зур минем, бабай, сез дә сыясыз", – диде. Ул, бабайны утыртып, минем янымнан выжылдап узып та китте.  Бабай бик шатланды.Миңа карады да малайны мактады: "Күрдеңме, кызым! Бигрәк яхшы малай икән! Капитан булыр ул!" – диде. (178 сүз)

(Д.Аппаковадан)

**МАКТАНЧЫК АЛМА**

Ямьле, җылы яз көнендә алмагач бакчасында булган бу хәл. Бакчада бер яшь алмагач үсеп утырган. Аның әле бер генә тапкыр да алма биргәне булмаган. Яз җиткәч, бер генә бөртек чәчәк аткан да алмага бөреләнгән. Тирә-яктагы үсемлекләр барысы да моңа бик куанганнар, яшь чибәркәйне тәбрик иткәннәр. Кошлар үзләренең иң матур җырларын юллаганнар. Олы агачлар бик сөенгәннәр, кортлар ияләшмәсен өчен, көндез дә, төнлә дә аны саклаганнар.

Алма көзгә бик матур булып кызарып пешкән. Уңыш җыяр вакыт җиткәч, аны да агачыннан өзәргә булганнар. Ләкин Алма:

— Мин, матур алма, өзеп ашар өчен түгел! – дигән дә яфраклар арасына кереп качкан. Шулай берзаман бөтен бакчага бер Алма булып калган. Шуннан соң ул:

— Күрдегезме инде, куркаклар, мин матур гына түгел, батыр Алма да бит әле! – дигән.

— Курыкмыйча, шундый зур бакчада минем кебек батырлар гына кала!

Бүтәннәр аның соңгы сүзләрен ишетмәгәннәр. Аларның кышка әзерлек эшләре башланган: яфракларын коясы, ботакларын корткыч бөҗәкләрдән чистартасы булган.

Шул арада, күптән инде җай гына чыкканын көтеп торган алма корты, сиздермичә генә менгән дә Алманы тешләп алган. Алма, авыртуына чыдый алмыйча, үрле-кырлы сикергән дә, агачыннан өзелеп, җиргә төшкән. Бер генә түгел, әллә нихәтле корт кимереп бетергән үзен. Һәр алманың үз вакыты, һәр эшнең үз җае барлыкны онытмаска иде шул аңа.(182 сүз)

(Алмаз Гыймадиевтан)

## Туган мәктәбем

Унынчы сыйныф укучылары, мәктәптә күптән килә торган гадәт буенча, бәйрәм көненә багышланган кичәгә спектакль әзерлиләр иде. Мондый кичәләр бер традиция булып киткәнлектән, аңа мәктәпнең барлык элекке укучылары катнашырга тырыша, килә алмаганнары хатлар, телеграммалар җибәрәләр. Шуңа күрә соңгы көннәрдә телеграмма ташучылар мәктәп юлыннан өзелмәде. Алар берьюлы бишәр-алтышар телеграмма алып киләләр. Мәскәүдән, Ленинградтан, Киевтан, Барановичидан, Одессадан, Владивостоктан – кайдан гына юк ул телеграммалар! Иптәшләр бәйрәмгә катнаша алмаулары өчен кайгыралар, ләкин бу көнне алар, кайда гына булсалар да, үзләрен тәрбияләп үстергән, кеше иткән кадерле мәктәпләрен, хөрмәтле укытучыларын сөеп искә алачакларын белдерәләр.

Спектакль иртәгә билгеләнгән булса да, бүтән шәһәрләрдән һәм районнардан килгән кунаклар мәктәпкә бүген үк җыела башладылар. Кайчандыр шушында укыган, ә хәзер кайсы укытучы, кайсы инженер, кайсы агроном, кайсы врач, кайсы очучы булып өлгергән дәү абыйлар, дәү апалар, укучы балаларны шаккатырып, сыйныф бүлмәләренә кереп йөрделәр, парталардан, тәрәзә төпләреннән, кара такта кырыйларыннан үзләренә генә билгеле булган ниндидер тамгалар табып, бер-берләренә күрсәттеләр, көлештеләр, тәрәзәләрдән үрелеп, каядыр тышка карадылар, матур оранжереяләргә охшаган, күз явын алырлык чәчәкләр, мәңге яшел үсемлекләр белән бизәлгән озын, якты коридорларда озак-озак сөйләшеп йөрделәр. (180 сүз)

(Г.Әпсәләмовтан)

## Икмәк

Кулыма икмәк алганда, еш кына сугыш еллары исемә төшә. Сугыш елларында күңелгә сеңеп калырлык күңелне тетрәндерерлек вакыйгалар шактый күп булды. Ләкин шуларның берсе аеруча хәтергә уелып калды.

Мин 1945 нче елның август башларында күргән бер күренешне оныта алмыйм. Без, бер группа солдат һәм сержантлар, туган илгә кайтып бара идек.

Һәркайда җимереклек, яндырылган авыллар, шәһәрләр. Авылларның исемнәре топографик картада гына калган. Исән калганнар, җимерекләрне бетерү, тыныч тормыш башлап җибәрү белән мәшгуль иде.

Шулай кайта торгач, безнең эшелон кечкенә генә станциягә килеп туктады. Төшәргә команда булмаганга күрә, без ачык ишектән генә тирә-якны күзәтеп торабыз. Шул вакыт безнең вагон янына 7-8 яшьләрдәге бик ябык малай килеп басты. Кызыксынып, бер сүз әйтмичә, малайны күзәтәбез, үзебезнең балаларыбызны күз алдына китерәбез. Аның көчсез генә тавыш белән " Абыйлар, ипиегез юкмы, ипи бирегезче", – дип соравыннан эсселе-суыклы булып киттек. Ул тавыш әле дә колак төбендә яңгырап тора шикелле.

Менә бит ул каһәр суккан сугыш! Без, аяусыз һөҗүмнәрдә иң якын дусларыбызны югалтканда да сыгылып төшмәгән кешеләр, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, читкә борылдык...

Башка станцияләрдә дә икмәк сораучыларны азмы-күпме шатландырдык, паекларны балаларга өләштек. Әмма беренче очраган малай онытылмый. Табынга утырган саен, икмәк сораган малай искә төшә. (181 сүз)

(Вакытлы матбугаттан)

## Әтием турында

Минем сезне әтием белән таныштырасым килә. Минем әтием – татар халкының танылган һәм талантлы композиторы Салих Сәйдәшев. Аның балачагы турында миңа әбием сөйли иде. Аның сөйләүләреннән мин шуны белеп калдым: әтием бик кечкенәдән музыка тыңларга, җырларга яраткан, гармунда уйнарга да бик иртә өйрәнгән.

Әтием көндәлек тормышта йомшак, иркен күңелле кеше булды. Мин аның безгә, балаларга, кычкырганын хәтерләмим. Ул, гомумән, тупаслыкны яратмый иде. Чыннан да, без аның Әминә исемле апасын бик яратуын, олылавын, шулай ук җизнәсе Шиһап Әхмәровны бик ихтирам итүен күреп үстек.

Миңа әтиемне иҗат итеп утырган чакларында күзәтергә туры килмәде диярлек. Ник дигәндә, ул пианино янында утырып эшкә тотынса, без аның бүлмәсенә кермәскә, мөмкин кадәр аңа комачауламаска тырыша идек. Дөрес, әсәрләрен иҗат иткәндә, ул шагыйрь яки драматург белән киңәшә торган иде. Бигрәк тә аның драматург Таҗи Гыйззәт белән бергә эшләгән чаклары минем хәтеремдә калган. Эш бүлмәсенә кермәсәм дә, кайвакыт аның уйнавын, көйләрен кат-кат тикшереп каравын сәгатьләр буе йотлыгып тыңлый идем.

Аның иң яратып башкарган көйләре – татар халык көйләре иде. Ә үз әсәрләрен ул бары тик тыңлаучылар соравы буенча гына башкара иде.

Минем әтием – Салих Сәйдәшев – тыйнак һәм эш сөючән кеше иде. (184 сүз)

(А. Сәйдәшев буенча)

## XI СЫЙНЫФ

## ДИКТАНТ ТЕКСТЛАРЫ

### Милли китапханә

Татарстанның Милли китапханәсе Казандагы иң матур йортларның берсендә урнашкан. Аның яныннан битараф кына узып китеп булмый. Бу бинаны фабрикант Ушков салдырган, соңыннан ул китап йортына әверелгән.

Заманының шактый зыялы кешесе И.А.Второв гомере буе китап җыйган. Аның китапханәсендә төрле телләрдәге китаплар, журналлар тупланган. Бу байлык мирас булып, аның улы – Н.И.Второвка күчкән. Николай Второв – Казанда җәмәгать китапханәсе ачылуга зур өлеш керткән кеше. Петербургка күчеп киткәндә, ул әтисе китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк иткән. Шулай итеп, 1865 нче елда Казанда китапханә ачылган.

Арыслан, төрле кош сурәтләре белән бизәлгән стеналар, борынгы баскычлар. Уңда да, сулда да, каршыда да – ишекләр, каталоглар, киштәләр…

Милли китапханәдә борынгы кульязмалар, сирәк китаплар бүлеге дә бар. Татар китаплары, туган якны өйрәнүгә багышланган басмалар бүлеге дә эшли. Дөнья әдәбияты, сәнгать бүлеге, фәнни-методик әдәбият бүлеге… Газета-журналлар өчен аерым бүлмәләр каралган. Бу йорт 3 миллионнан артык китапны сыйдыра.

Белеп торыгыз: биредә беркайчан да “китап юк” димиләр. Үзендә кирәкле китап юк икән, компьютерга басып, университет китапханәсеннән, бөтен Татарстаннан эзлиләр. Анда да бу китап булмаса, Россия Дәүләт китапханәсенә яки Санкт-Петербургның Үзәк китапханәсенә мөрәҗәгать итәләр. Инде әлеге китап анда да юк икән, чит ил китапханәләренә чыгалар. Милли китапханәдә халыкара китап алмашу бүлеге бар. Татарстанның Милли китапханәсе дөньядагы 83 илнең китапханәләре белән килешүләр төзегән… Кешелекнең чын тарихы Китап дөньяга килгән чордан башлана. Китап, халыкларны гасырлар буена тәрбияләп, ышаныч һәм өмет биреп, киләчәккә алып барган. (212 сүз)

(“Татарстан Республикасының Милли китапханәсе” китабыннан)

### Укытучым

Менә көз җитте. Укулар башланды.

Безне яклар өчен сәер яңгырашлы Демченко фамилияле апа безнең мәктәптә рус теле укыта башлады. Аны барысы да бик яраттылар.

Аның ире очучы икән. Ул сугышта. Ә Анна Сергеевна гомердә күз алдына китермәгән татар авылында балалар укыта. Аңа бик еш хатлар килә. Андый көннәрдә ул бик шат күренә. Ә кайчакта уйчанланып китә. Кич улы белән урамда йөри, чишмә буйларына төшә.

Уку елы тәмамланды. Берничә көн узгач, авылга авыр хәбәр килде: Петяның әтисе һава сугышыннан соң кире кайтмаган. Бу хәбәрдән соң апа бер атна авырып ятты, төсе качты. Ә беркөнне минем укытучы апам кинәт юкка чыкты. Аның кая киткәнен беркем дә белми калды.

Күп еллар үтте. Анна Сергеевна укыткан балалар, үсеп, күптән инде төрле өлкәләрдә илебезгә хезмәт итәләр. Ләкин күңел түренә кереп урнашкан укытучыны беребез дә онытмады. Соңгы көннәрдә үзәк газеталарның берсендә басылган искиткеч бер хәбәр кадерле укытучымны тагын күз алдына китереп бастырды.

Белоруссия сазлыкарын киптереп, трактор белән сөргән вакытта, самолет калдыклары табылган. Тимер-томыр арасыннан очучының сөякләре килеп чыккан. Көмеш портсигарында исем-фамилиясе сакланган икән. Игенчеләр якындагы хәрби бүлеккә хәбәр итәләр. Ватан сугышында геройларча һәлак булган очучыны кадерләп күмәләр, портсигарда язылган исеме буенча, кабер өстенә “Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган очучы А.М. Демченко” дип язып куялар. Шул ук вакытта газетада, очучының Ватан сугышында күрсәткән батырлыгын искә алып, хөкүмәт тарафыннан аңа, үлгәннән соң, Герой исеме бирү турында хәбәр ителә. Геройның Анна Сергеевнаның ире булуы турында һич шик юк иде. Бу хәбәр яшен тизлеге белән бөтен авылга таралды. (224 сүз)

(Г. Бакирдан)

### Урманда

Бүген алар урманга барырга уйладылар. Күбесенең туган көннәре бер тирәдә. Гөлнараларның сыйныфы унбиш яшьләре тулганны билгеләп үтәргә булды. Соңгы уку елында матур хатирәләр калсын әле.

Алар урманга килеп җиткәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Агачлар тагын да яшәреп киткәндәй тоелды. Чәчәкләр дә көндәгегә караганда матуррак!

Тирә-якка соклана-соклана сукмактан кереп барганда, Гөлнара кычкырып җибәрде: «Ә без бит әле урманнан рөхсәт сорамаган!» Бу сүзләрдән кайсы көлде, ә кайберләре тезелешеп басып: «Урман бабай, керергә мөмкинме? Мөмкин булса, бер кошыңны сайратчы», – диде. Шулчак, чыннан да, бер кошчык бик моңлы итеп сайрап җибәрде.

Сыйныфташлары уйнаганда да, бәрәңге пешергәндә дә, ул эшчән кырмыскаларны карап, урман докторы тукранның тавышын тыңлап йөрде. Табигать барысын да аңлый, ә дус егетләре, кызлары ни өчен аңламыйлар соң аны?

Сәеррәк шул ул: башкалар кочак-кочак чәчәк җыйганда да Гөлнара берничәне генә өзә; иптәшләре агач ботагын сындырганда да үзенең кулларында авырту сизгәндәй була.

«Аерылып йөрү килешмәс», – дип, Гөлнара дуслары янына килде. Сөйләшеп, көлешеп утыргач, кәефе дә күтәрелеп китте. Кайтыр вакыт җитте.

Алар җыена башладылар. Гөлнара консерв банкаларын, кәгазь кисәкләрен җыярга тотынды. Бер-ике иптәше дә аңа килеп кушылды. Урманны пычратып калдырырга ярамас! Кайбер сыйныфташлары: «Җыегыз, җый!» – дип көлештеләр. Әмма ул бер сүз дә дәшмәде, йөрәге әрнеп уйлады гына: «Юк, аңламыйлар мине. Әнә тукран да агачларны кортлардан коткара, кырмыскалар да урманы чистарта. Ә без?» (213 сүз.)

(Ф.Бәдретдиновадан)

**Урманда**

Урманга килеп кергәч, һаваның сафлыгыннан хәтта баш әйләнеп киткәндәй булды.

Гафур бабай, бераз машина йөргән юлдан барганнан соң, малайларны җәяүлеләр юлыннан алып китте. Инде кояш та агачлар арасыннан күренә башлаган иде. Бераздан юл бормалы тар сукмакка әйләнде. Аның буйлап бара торгач, аланлыклар күренә башлады.

— Килеп җитәбез, ахры, — диде Кәрим, олыларчарак итеп.

— Әйе, — диде Дамир, — әнә нинди җиләклекләр китте!

Барып җитәргә иртәрәк икән әле. Гафур бабай, кырт кына борылып, малайларны уңга алып кереп китте. Бусы инде алар өчен махсус югалту белән бер иде. Шуңадыр, мөгаен, иптәшләреннән күбрәк белгән Кәрим дә:

— Кире авылга кайтып, юлдан яңадан килергә кушсалар, мин тар сукмакка кадәр генә килә белер идем, — дип, үзенең юл югалтканын танырга мәҗбүр булды.

— Аңа кадәр мин дә килә алыр идем, — диде Дамир, сер бирәсе килмичә.

— Һай, болай булгач, сезгә ышанып ерак китәрлек түгел икән әле, дип кеткелдәде аларның сүзенә колак салып барган Гафур бабай. – Күз алдыгызда торган урманга кереп, өч-дүрт чакырым да үтмәдек, юл югалтып, бутала, адаша да башладыгыз. Ә бит бернинди ориентир приборлары алмыйча, хәтта тайганы гизеп йөрүчеләр бар!

Гафур бабай моны шаяртып кына әйтте, билгеле. Ул белә, урманда ерак китеп йөргәне булмаган малайларга әледән-әле алышынып торган юллар белән сукмакларны хәтергә салып бетерү мөмкин түгел иде. Шуңа күрә дә алар аның сүзләреннән соң, чиксез океаннар, калын урманнар һәм миражлы чүлләрне гизеп йөрүче кыю кешеләрне күз алдына китереп, бер мәлгә уйга калдылар.

Мондый матурлыкны күрмичә үсүче шәһәр малае Таһирҗанга урман аеруча серле, могҗизалы булып күренде. Ул үзен икенче дөньяга эләккәндәй хис итеп, монда күргәннәрнең бөтенесен хәтеренә сеңдереп барырга тырышты. (220 сүз)

(Заһит Фәйзидән)

## Елга буенда

Таһирҗан эшлисе эшләрен бетерүгә, алдагы көн өчен уку әсбапларын карап-әзерләп куйды да, иң яраткан җиренә – Казансу буена китте.

Бүгенге Казансу аны аеруча тарта иде. Ул, бөтен көч-гайрәтен күрсәтергә теләгәндәй, ярларыннан тулып ашкан.

Таһирҗан, кызу-кызу атлап, елга буена бара. Елгага якылашкан саен, аңа рәхәтрәк тоела, җанына нindидер җиңеллек бөркелә бара иде.

Ул су буена тезелгән таллар янына килеп җиткәч, тукталып, тынып калды. Җылымса җил шундый ягымлы, ләззәтеннән күзләре йомыла. Әйтерсең, аның битен әнисенең йомшак кулы иркәли! Таһирҗан, калкурак җиргә басып, ургыл агымны күзәтә башлады.

Казансу ярларыннан ашып, әллә нинди куркыныч чоңгыллар ясап агучы ташкынга әйләнгән. Аның, болганып, кызыл-кучкыллы булган суында йә көтүе-көтүе белән, йә берән-сәрән булып эреле-ваклы бозлар, агач кисәкләре, ташландык әрҗәләр һәм санап бетергесез күптөрле чүп-чар агып бара. Соңгылары чисталыкка битараф, бер-берсенә хөрмәтсез һәм культурасыз бәндәләргә ләгънәт укып үтәләр әйтерсең. Язгы агымнар бу күңел кайтаргыч чүп-чар һәм ташландык әйберләрне агызып алып китсә дә, алар, кая да булса башка җиргә барып, андагы матурлыкны, андагы тормыш ямен киметәчәкләр.

Төркемләшеп агып барган бозлар, урыны-урыны белән кызулап китеп, берсен-берсе куып җиткәндә, бәрелешеп, пыяла кебек чәлпәрәмә киләләр. Икенчеләре дә, чоңгыллы бөтеремгә җиткәч, бәрелешеп, таркала. Тик берсе генә дә үзеннән алдагыларны кабатламый. Һәркайсы үзенчәрәк агып килә һәм үзенчәрәк таркалып юкка чыга. “ Ә бит кешеләр тормышы, кешеләр язмышы да шулай, – дип куйды агымга карап уйга калган Таһирҗан. (208 сүз)

(Заһит Фәйзидән)

## Чишмә

Зөфәр балачактан урманда йөрергә, кошлар сайраганны тыңларга ярата. Менә бүген дә иртән торуга, тиз генә киенде дә урманга китте ул. Урман эчләп бара торгач, Зөфәр бер тау буена килеп чыкты. Тауны чыршы, нарат, шомырт агачлары каплаган. Таудан да гаҗәбрәге алда икән.

— Чишмә! — дип кычкырганын сизми дә калды Зөфәр.

Җырларда макталган, әкиятләрдә тылсым иясе булып гәүдәләнгән чишмә. Үз урманнарында чишмә барын Зөфәр моңарчы ничек белми йөрде икән? Әнә ул ярга сыенган ташлар арасыннан, агач тамырлары өстеннән, җырлый-җырлый, түбәнгә сикерә. Кайдан килә ул, кем аңа юл ачып җибәргән?

Зөфәр табигатьнең оста кулы озак еллар буе шомартып ясаган ак таш урындыкка килеп утырды. Савытын алып, чишмә суын тутырды. Салкынлыгы тешеңне сындырыр. Бу эсседә күп эчәргә ярамый. Зөфәр тирләгән битен, башын боздай салкын су белән юды да чишмә кырыендагы әле яшеллеге

бетмәгән, үзенә бер тәмле ис аңкып торган үләнгә сузылып ятты. Табигате бигрәк матур һәм бай шул туган илебезең!

Чишмә. Сусап, арып барган юлыңда чишмә очраса – нинди бәхет. Чыннан да тылсым иясе ул. Сиңа көч, куәт биреп җибәрә. Аннан соң озак еллар буена шул чишмәне сагынып сөйлисең. Ә менә бу чишмә? Ул күпме кешенең юлында очраган, кемнең сусавын кайтарган, кемнең ярасын юган, кем белән ерак юл үткән? Бәхетлеме бу чишмә? Еракта калган бәхетен сагынамы? Яки алдамы әле аның бәхете?

Чишмә бу турыда сөйлидер, бәлки җырлыйдыр. Аның телен аңлап булмый шул.

Шулай да үзеңнең чишмәңне табу – зур шатлык. (220 сүз)

(Г. Нәбиуллиннан)

## Менә кем иде ул Алиш

Кем соң ул Алиш?

Абдулла Алиш балаларны бик яраткан, алар өчен әкиятләр, шигырьләр, кечкенә хикәяләр язган, ләкин явыз сугыш аның гөрләп торган эшләрен бүлә. Меңләгән кешеләр белән бергә Алиш сугышка китә.

Абдулла Алиш туган илен бик ярата, ул чын патриот була. Яраткан язучыбыз Аркадий Гайдар кебек, кулына корал тотып, Ватанны фашистлардан саклый. Ул бик батыр солдат була, бернәрсәдән дә курыкмый. Каты яраланып, 1941 нче елның октябрендә Дёсна елгасы буенда дошман кулына төшкәч тә, ул аңа баш ияргә уйламый. Аны Алитус лагерена ябалар, аннары Чехословакиягә, Германиягә озаталар. Алиш, тугрылыклы иптәшләре белән бергә, качу турында хыяллана, ләкин алар кача алмыйлар, серләре ачыла. Шуннан соң аларны бик каты газаплыйлар, ашарларына берни дә бирмиләр.

Лагерьларның берсендә Алиш Муса Җәлилне очрата. Алар бер-берсен элек-электән яхшы беләләр, икесенең дә йөрәгендә фашистларга карата нәфрәт уты яна. Алар соңгы сулышларына кадәр көрәшергә ант итәләр. Дуслар бергәләп листовкалар язалар. Фашистлар хәрби әсирләрдән легионнар төзи башлагач, әсирләргә фашистлар сүзенә ышанырга ярамавын, илгә хыянәт итү – иң зур җинаять икәнен аңлаталар. Аларның агитацияләре уңышлы була. Легионерлар, фронтка җибәрелгәч, үзләренең немец командирларын үтереп, партизаннар ягына чыгалар.

Шуннан соң гитлерчылар шикләнә башлыйлар. Ниндидер бер сатлык җан аларга яшерен оешма турында әйтә. Муса Җәлил, Абдулла Алиш һәм аларның якын дуслары, кулга алынып, Моабит төрмәсенә ябылалар. Биредә аларны тагын бик каты газаплыйлар, ләкин алар дошманнан шәфкать сорамыйлар, батырларча һәлак булалар. (226 сүз)

(*Г. Әпсәләмовтан)*

## Көтелмәгән кунак

Безнең солдатлар иртәнге ашны ашап кына бетергәннәр иде. Кинәт югарыда, окоп өстендә, мәче тавышы ишетелде. Бер сержант саклык белән генә торып караган иде, анда кечкенә генә соры песи баласын күреп алды.

Шундый салкын көндә песи баласы килсен, имеш. Әйләнә-тирәдә кара урман. Алда ерак түгел генә бер авыл күренә. Бу авылның өйләре сугышта җимерелеп беткән. Тик ара-тирә җимерек өйләрнең бүрәнәләре генә тырпаеп торалар иде.

Бу авыл фашистлар кулында. Песи баласы, азык эзләп, кешеләр янына килгән булырга кирәк. Әйтерсең ул да ерткыч фашистлардан качкан. Песи баласы, окопка керү белән, элек бөтенесен иснәп чыкты да кызганыч тавыш белән мияулап җибәрде. Кунакка аш салып бирделәр. Ашагач, аның күзләре матурланып китте, әзрәк уйнады да почмакка барып йокларга ятты.

Песиләр торган җирләрен сагынучан булалар. Әлеге сержант песи баласын алды да окопның кырыена куйды. Песи әзрәк басып карап торды да авылга таба йөгерде.

Икенче көнне иртән песи баласы тагын окопка килде. Бу юлы инде ул мияуламыйча гына окопка үзе сикереп төште дә тиз генә савыты янына килеп ашый башлады.

Песи баласы безнең солдатларгаияләшеп китте. Көн дә иртә белән килә дә, кичкә кадәр окопта йоклап, тамагын туйдырып, кич белән үзенең туган авылына кайтып китә торган булды.

Сержант, песи баласын авылга озаткан вакытта, һәрвакыт аның аркасына фашист солдатларына мөрәҗәгать итеп язылган бер-ике листовка бәйләп җибәрә торган булды. Шулай итеп песи баласы унбер тапкыр окопка килде һәм унбер тапкыр ул безнең листовкаларны дошманнарга алып барды. (220 сүз)

А. Шамов буенча

## Айдар

Бу ятимнәр йортында әнисез яки әтисез балалар күп. Әтисез-әнисез балалар да бар. Кайберләренең әти-әнисе генә түгел, әби-бабасы, туган-тумачасы да юк. Анысы гына нәрсә... Айдарның туган көне дә юк хәтта. Барлыкка бар, тик дүрт елга бер генә килә. 29 нчы февраль көнне туган шул ул, кәбисә елны. Шуңа күрә, бер мәртәбә үткәрә дә, өч ел рәттән туган көнсез, бәйрәмсез яши. Бу балалар йортына килгәч, ул әле бер дә үткәрмәде туган көнен.

Ә ятимнәргә туган көн бик кирәк. Туган көннәрен билгеләүче балаларга бу көнне тәмле ризыклар бирәләр, яңа киемнәр кидерәләр, алар янына туганнарын, дусларын чакыралар... Иң мөһиме: бу көнне аларны кыйнамыйлар. Хәтта иң усаллардан саналган Хәмис тә андыйларга кул күтәрми. Шундый тәртип.

Айдарга көн саен диярлек “өлеш” төшеп тора. Буйга кечерәк шул ул. Тәнендә, буыннарында көч җыелып, урнашып кына килә. Җитәр бер вакыт,

Айдардан да көчлерәк малай булмас, бөтен кеше аңа карап торыр. Бүген исә ул, сигез яше тулуга карамастан, һаман үзеннән кечерәкләр белән уйный, бүген ул яклауга мохтаҗ, туган көнгә мохтаҗ...

Кызганыч,быел да 28 февральдән соң 1 март килде. Быел да Айдар туган көнсез калды. Иртән торуга ук, түшәгенә капланып, елап алды. Юк, беркемгә дә рәнҗеп яисә үпкәләп еламады ул. Ләкин тиккә дә еламады. Бүген тагын кыйналасын белеп, шул кыйналган вакытта еламас өчен елады. Чөнки белә: алдан елап, күз яшьләреңне түгеп, күңелеңне бушатып куйсаң, соңыннан, ничек кенә кыен, авыр булса да, еламый калырга мөмкин. Артык горур шул ул. Хәмис аны күпме үз янына алырга, үзенә йомышчы итәргә тырышып карады. Айдар барыбер баш бирмәде, кыйналса кыйналды . әмма Хәмиснең куштаны булмады. (219 сүз)

Г. Гыйльманов буенча

**Икмәк**

Бу сүз – ана исеме белән торырлык олы сүз. Икмәк турында бер генә көн уйламый калган кеше бармы икән дөньяда? Күпме шигырь, күпме роман язылган икмәк турында! Шулай да мин үземнең сүзләремне “Без икмәкне ихтирам итә беләбезме?” дип башларга телим.

Беркөнне бер танышым белән иртәнге тыныч, матур вакытта Аккош күле янындагы яшел алан аша сузылган сукмак буйлап сөйләшә-сөйләшә кайтып килә идек. Менә шушы карап туймаслык гүзәл аланда, аллы-гөлле чәчәкләр үскән палас өстендә ертылып ташланган газета кисәкләре, буш консерв савытлары, шешә ватыклары күреп сәерсенеп калдык. Хәтта бер агач төбендә бербөтен икмәк аунап ята иде.

Үзебез дә сизмәстән шул икмәккә карап тукталдык та телсез калган кебек булдык. Шулай рәхимсез ташланып калдырылган изге икмәк өчен безгә бик уңайсыз булып тоелды. Дөресен әйткәндә, без оялдык. Кемнеңдер бу мәрхәмәтсезлеге өчен без дә җаваплы идек шикелле.

Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез бәндәнең исеме ничек? Ул икмәкнең нәрсә икәнлеген, кайда һәм ничек үскәнлеген беләме икән?

Юктыр. Әгәр ул икмәк үскән җирләргә яңгыр гына түгел, бәлки игенченең маңгай тирләре тамганны белсә, иген үскән җир туфрагында кояш җылысы гына түгел, хезмәт кешесенең күңел җылысы да калганлыгын белсә, болай эшләмәс иде. Урамнарда, паркларда, вокзал буйларында аунап яткан икмәк телемнәре булмас иде. Аңа намусы мондый эш эшләргә рөхсәт итмәс иде. Ул беркайда да язылмаган законны белер иде Бу закон икмәккә ихтирам, кешегә мәхәббәт турында. Аны үтәү – һәркемнең изге бурычы. (218 сүз)

(Н.Дәүли буенча)

## ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗДЫРУ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

### Дан сиңа, туган илем!

Җиңү!

Менә ул, язгы бәрәкәтле яңгыр алдыннан күк күкрәгән төсле тавыш чыгарып, бәйрәм салютларыбыз яңгырый һәм энҗе кебек якты ракеталарның нуры белән тыныч күгебезне балкыта. Бу көн бик азга гына булса да югалту кайгысын, ачысын оныттырып торды. Бөтен ил шатлык кочагына ташланды. Бик кыйммәт бәя түләнгән шатлык көне иде ул.

Без аңар дүрт елдан артыкка барган сугыш ялкыны һәм янгын төтене аша килдек. Илебезнең йөрәге – изге Мәскәү янындагы траншеялардан, Идел дәрьясының текә ярларыннан килдек. Шәһәрләребез, авылларыбызны азат итү өчен барган көрәшләрдә батыр сугышчыларыбызны югалттык без.

Йөрәкләребездә:

– Җиңү безнең якта булыр! – дигән нык иман белән килдек.

Һәм менә ул – яхшылыкның явызлыкны тарихта беренче тапкыр шушындый бөек тантана белән җиңүе! Фашизмның канлы байрагы бәреп төшерелде. Безнең урамда хәзер бәйрәм!

Җиңү!

Кырык беренче елның кызу җәендә авылларыбызны, шәһәрләребезне җимергәндә, кырларыбызда үскән игеннәребезне танклар таптаганда ул әле алга чакыручы өмет иде. Туганнарыбызны, газиз кешеләребезне караңгылатылган юллар буенча озатканда һәм алардан борчылып хат-хәбәр көткәндә, без аның турында хыяллана, уйлый гына идек әле. Бүген ул чынбарлыкка әйләнде һәм дошманның башкаласы өстендә, экияттәге ут кошы төсле, ал байрак булып югары күтәрелде. (176 сүз)

(Кави Нәҗмидән)

### Дуслар

Миша – рус малае. Татарлар янында үсте. Бик әйбәт татарча сөйләшә, татар җырларын яратып җырлый. Башта әтисе аны шәһәргә рус мәктәбенә укырга бирде. Ни өчендер, Миша бик авыр укыды, бигрәк тә арифметиканы аңлый алмый иде. Миша уенны бик ярата иде шул. Татар малайлары белән уйнау комачау итә, дип сөйләнде әти-әнисе. Тиздән аларга шәһәрдән квартира бирделәр. Анда Миша яхшы гына укып китергә тиеш иде, тик алай булып чыкмады.

Миша Идел буен оныта алмады. Балачактан ук балык тотарга яратты. Озаклап Идел яры буенда уйланып утырырга ярата, үсемлекләр, бөҗәкләр белән сөйләшә, табигатьне тыңлый белә. Андагы бу сәерлекләрне Тәүгиз кенә аңлый. Шуңа күрә Миша укуда начар билге алса, өйдә берәр күңелсезлек чыкса, тизрәк Тәүгизләргә килеп җитә. Менә бүген дә мәктәптән Миша туры аларга кайтты.

Алар сарайдан озын-озын кармаклар алып чыктылар.

— “Нота” шигырен ятларга бирделәр, — диде Тәүгиз. — Моннан элек “Мокамай”ны сөйләттеләр. Миша да Такташның берничә шигырен яттан белә иде.

Тәүгиз гаиләдә бердәнбер бала иде. Алар зур, якты, яңа йортта яшиләр. Мишалар алты бала үстеләр, аларның йортлары да кечкенә генә иде. Аның әти-әниләре шәһәргә күчү теләге белән яшәгәнлектән, йортларын яңартмадылар. Шуңа күрә Миша гел Тәүгизләрдә булды, хәтта аларда кунарга да кала иде. Шул вакытларда алар шигырьләрне бергә ятладылар. (180 сүз).

**Оҗмах кошы**

Әбисенең әкият сөйләгәнен тыңларга ярата Ләйлә. Тавышы шундый йомшак, утырган җирдән изрәп, татлы йокыга киткәнеңне сизми дә каласың. Ә әкиятләре – тын да алмый тыңларлык кызык, каян шулкадәр белеп бетерә торгандыр.

— Борын-борын заманда, саескан сутник, үрдәк үрәтник булганда — дип, ул бүген оҗмах кошы турында әкият сөйләде. Оҗмах кошы Ләйләгә хәтта төшенә дә керде. Нәкъ әбисе сөйләгәнчә, аллы-гөлле каурыйларын балкытып, шау чәчәкле оҗмах бакчасында кукыраеп йөри имеш. Шул кошның канатына гына кагылсаң да дөньяда иң бәхетле кеше буласың икән.

Бәхет дигәне нәрсә буладыр инде. Ләйлә бик аңлап бетерми. Аңа бит әле биш яшь кенә. Әтисе әнисенә: “Син – минем бәхетем!” — ди. Әнисе Ләйләне кочаклап: “Син – минем бәхетем! – ди”. Матур күлмәк алсалар – бәхет, шоколад белән сыйланса – бәхет, әнисе эшенә алып барса – бәхетнең дә бәхете!

Беркөнне әбисе каты авырып китте, урыныннан тормас булды. Бик борчылды Ләйлә. Инде аңар әкият сөйләр кеше дә калмады....

Кызчык әбисе яткан бүлмәгә кереп китте. Нәни учларын әбисенең маңгаена куйды, мәтрүшкәле чәен эчәргә булышты. Бүген Ләйлә үзе аңа оҗмах кошы турында әкият сөйләде.

— Менә ул кошны әтием тотып алып кайтса, син терелер идең, әйеме, әбием! – дип хыялланып та алды. Әбисе хәлсез куллары белән оныгының чәченнән сыйпап елмайды:

— Оҗмах кошым – ул син, нәп-нәни зу-у-ур бәхетем! *(186сүз)*

*(Р.Шәриповадан)*

**Таныш моң**

Ул кичне фронттан аеруча күңелсез хәбәр килде.

Күземә йокы кермәде. Ниндидер ташландык бер сарайда бөркүдән һәм авыр уйлардан йоклый алмый газапланып ятканнан соң, урамга чыктым. Урам буш һәм тын иде. Үз-үземне кая куярга белмичә, ачынып, тротуар буйлап киттем, көннең суыклыгын да, урамның караңгылыгын да тоярлык хәлдә түгел идем. Патрульләр берничә мәртәбә туктатып, пропуск сорады.

Күпме йөргәнмен, хәтерләмим. Ничектер, тар гына бер тыкрыкка барып чыктым. Шунда кинәт тынып калдым. Каяндыр әкрен генә, зәгыйфь кенә булып скрипка тавышы ишетелә иде. Башта мин колакларыма ышанмадым. Саташам дип торам. Безнең көй бит бу! Татар көе! “Әллүки”! Туган яклардан еракта әлеге көй аеруча кадерле иде.

Мин, аның әкрен генә, зәгыйфь кенә чыккан моңы агышына бирелеп, дөньядагы барлык нәрсәмне оныттым, берничә минут шулай басып тордым. Көй берничә тапкыр кабатланды. Ул һәр юлы, үзенең һәр авазы белән мине биләгәннән-били барды. Мин, ниндидер эчке көчкә буйсынып, аны эзләп, ишегалдына кереп киттем. Ләкин ул анда, мин кергәч, кинәт югалды.

Яңадан урамга атылып чыктым. Инде ул урамда ишетелми иде. Югалды...

Юк, югалмаган икән, ул яңадан яңгырый башлады. (182 сүз)

(Афзал Шамовтан)

## Туган тел

Ничек дип игълан иттеләр әле? «Татарстаннан Ленар Самат улы Вәлиев, Иоһанн Себостьян Бах сонаталарын башкарып, беренче урынны алды», - диделәр. Ленар сәхнә уртасына Татарстан флагын күтәреп чыкты. Кул чаптылар! Зал Татарстанны, аның яшелле-аклы-кызыллы әләмен алкышлады.

Ленар микрофон янына килеп рәхмәт әйтә башлады. Шунда алдагы рәтләрдә утырган берәү саф татар телендә:

— Татарча әйт, татарча, син бит – татар малае! – дип кычкырды. Аңа тагын берничә кеше кушылды. Ленар каушады, чөнки ул татарча белми иде. Элегрәк, авылга кайтып йөргәндә, әбисеннән бераз өйрәнгән иде. Соңгы елларда кайтмый башлады шул. Ә элек белгәннәрен генә оештырып әйтә алмас, мөгаен. Шулай да бөтенләй дәшми калырга теләмәде Ленар.

— Рәхмәт... мин... әни... әти... Татарстан... яратам... – диде ул. Шунда ук бераз читтәрәк, затлы урындыкларга утырган әти-әнисенә карады. Ничектер кечерәеп калганнар иде алар. Хәзер генә, талантлы уллары белән горурланып, башларын күтәреп утырган ата белән ана бу минутта бәхетсез, хәтта сагышлы иде.

Ленар аларга ике төрле сүз белән, дөресрәге, хис белән карады. Беренче караганда: «Берәр ничек ярдәм итегез инде, бөтен ышанычым сездә», – дип караса, бераздан аның карашында: «Нәрсә инде бу? Нигә мине татарчага өйрәтмәдегез?» – дигән моңсу сорау барлыкка килде.

Шунда ук күңелендә ныклы бер уй туды: «Исән-сау Казаныма кайтсам, икенче көнне үк авылга, әбекәй янына китеп, туган телемне ныгытып өйрәнеп киләм. Дәресләрне, музыканы, котлауларны ташлыйм да кайтып киләм!..» (181 сүз).

(Г. Гыйльмановтан)

## Татарларның милли бәйрәме - Сабан туе

Сабан туе – элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. Сабан туе – ул язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу, булачак уңыш бәйрәме. Борынгы чорларда Сабан туе яз һәм табигатьнең җанлануы бәйрәме булган. Аның мең еллык тарихы бар. Сабан туе бәйрәме Идел буе Болгары дәүләтендә үк уздырылган булган.

Сабан туе Идел буенда яшәгән барлык милләтләрнең дә уртак бәйрәменә әйләнде. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар да катнаша.

Сабан туенда иң зур ярыш – көрәш. Татар көрәшендә сөлге тотып көрәшәләр. Һәр көрәшче көндәшенең биленнән сөлге белән урап тота һәм аны җиргә егарга тырыша. Көрәшне малайлар башлап җибәрәләр. Аннары , чиратлашып, мәйданда яшүсмерләр, егетләр, урта яшьләрдәге ирләр көрәшә. Көндәшен аркасына яткырган кеше җиңүче була. Көрәштә батыр калучыга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр.

Сабан туенда икенче зур ярыш - ат чабышы. Атлар 5-8 километр ераклыктан мәйданга чабып керәләр. Бу ярышта беренче килгән атның хуҗасына да зур бүләк бирәләр, ә атның муенына яулыклар, сөлгеләр бәйлиләр. Иң соңыннан килгән атның хуҗасы да бүләксез калмый.

Мәйданда кызыклы халык уеннары оештырыла. Ярышлар һәм уеннар беткәч, кешеләр өйләренә таралалар. Һәр йортта табын әзерләнә, бәйрәм ашлары пешерелә. Кичен яшьләр өчен җыр-биюләр дәвам итә.

Сабан туе – күңелле һәм шатлыклы бәйрәм. (180сүз)

(Вакытлы матбугаттан)

## Яшәү өчен көрәш

Тормыш бераз эзгә төште. Күңел басылды. Иркенләп язарга, укырга мөмкинлек туды. Больницадагы кебек, кырыеңда ыңгырашып ятучылар юк. Карарга әнисе бар. Аналарның бөтен мәхәббәте, бөтен җылысы ярдәмгә мохтаҗ балаларга тиючән. Фәнияр да бу хакта белә: язмыш ныграк кыерсыткан саен, әнкәсенең якынлыгын күбрәк тоя ул. Ананы дөньяда һични алыштыра алмый. Ул – кешелекне тотып торучы алтын багана. Әмма яшьлек ярсуыннан тау чишмәседәй ургып торучы йөрәккә ана назы гына аз, ана кайгыртуы гына җитми. Күңел үзенең ишен эзли. Куанычларың булганда бергә куанырлык, кайгы-хәсрәт килгәндә – юатырлык, егылганда – кул сузарлык, ялгышканда – төзәтерлек, эшләп арганда – иркәләрлек, назга сусаганда кочагында эретерлек кеше табасы килә. Ә Фәнияр кебек кешеләргә иш табу кыен эш. Шуңа күрә ул үзенең авыруын капларлык эшләр башкарырга, тормышта яшьтәшләреннән бер як белән дә калышмаска тели, туктаусыз көрәшә. Фәниярга бер генә җиңүнең дә көрәшсез килгәне юк әле. Кулына каләм тотып бер юл шигырь язар өчен дә, замандашларыннан артта калмаска теләп, тырышып-тырышып укыр өчен дә,

хәтта мәхәббәт өчен дә көрәшергә, язмыш куйган ятьмәләрне ертырга кирәк аңа. Көрәш ул, Сабантуйларда кулыңа тастымал урап, кемнәрнеңдер биленнән алу гына түгел. Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт: көчлеләр ега, көчсезләр егыла. (180 сүз)

(Ф.Яруллиннан)

## Урман

Аю, икесе дә бертөрле бик озын һәм бик яшел ике агач янына килеп, алар белән дә танышты. Болар Нарат Нуриев белән Чыршы Шәрипов иде. Алар сүзне болай башлап җибәрделәр:

— Безнең кадеребезне, матурлыгыбызны беләсең килсә, Аю агай, син бөек шагыйрь Г.Тукай шигырьләрен тыңлап кара һәм илебезнең олы рәссамы И.Шишкин картиналарына күз сал. Безне мактап, тиккә генә шигырь язмаганнар, безнең матурлыгыбызга сокланып, тиккә генә картиналар эшләмәгәннәр алар. Аннары шуны да әйтеп үтик, Аю агай: безне бит теләсә нинди төзелешләрдә дә файдалана алалар.

Аю, агачлар белән саубуллашып, өенә кайтырга җыенганда гына, Урман телгә килде:

— Мин билэп торган мәйдан болай гына түгел иде. Ләкин ниндидер саксыз кешеләр, янгын чыгарып, мине харап иттеләр. Әгәр миндәге бик күп агачларны олы кешеләр дә, балалар да сакласалар, аларны урамнарга, бакчаларга, паркларга, юл буйларына күпләп утыртсалар һәм яхшылап карап үстерсәләр, бу агачлар бөтен дөньяны яшеллек белән каплап алырлар иде. Агачлар, яшеллек үскән җирдә һава саф була. Урман эчендә җәнлекләр үзләренә оялар, өннәр ясыйлар, балаларын үстерәләр. Минем аланнарымда тәмле җиләкләр, матур чәчәкләр, файдалы дару үләннәре үсә. Мине саклагыз, хәзинәләремнән авыз итегез, егылган агачлардан чистартыгыз.

— Бу мәгънәле сүзләрне онытма, тизрәк яз! – диде Аю Куянга. (180 сүз)

(Г.Галиев буенча)

## Онытасым юк

1943 елның 1 гыйнвар көнен мәңге онытасым юк. Ватан сугышының иң кызган көннәре, Сталинград өчен аяусыз сугыш бара. Безнең эти дә шунда. Шулар өчен кайгырып яшибез. Укытучыларыбыз, безнең күңелне күрер өчендер инде, 1 гыйнвар көнне мәктәптә Чыршы бәйрәме оештырдылар.

Бәйрәмгә сәгать тугызга килергә әйтелгән иде. Ни җаның белән сәгать тугыз тулганны көтеп ятмак кирәк?! Һәрберебезгә бүләкләр бирмәкчеләр икән. Бәлки әле берәр сынык ипи дә эләгер. Бәрәңге шулпасы эчеп яшәүче бала-чага өчен моннан да зуррак бәйрәм була аламы соң?!

Иртә таңнан мәктәп ишегалды гөрләп тора иде инде. Салкынга бирешмәс өчен, бала-чага этешә-төртешә, йөгерешә, узыша. Минем никтер иртәдән үк эчем поша, бер дә юкка елыйсы гына килеп тора. Концертта да теләми генә биедем. Аннары бәйрәм беткәнне көтеп тә тормый, бер сәбәпсез елый-елый

кайтып киттем. Өйдә этидән бүген дә хат килмәгән...

... Бер атнадан соң этинең нәкъ менә 1 гыйнвар көнне каты ярадан госпитальдә вафат булуы турында кара мөһер сугылган кәгазь алдык. Әтинең ул көнне госпитальдә үлем белән тартышып ятуын мең чакрымнар аша минем күңелем сизгән.

Әти Берлинга барып җитә алмады. Аның хөрмәтенә Берлинның Трептев паркындагы солдат һәйкәленә чәчәкләр илтеп салдым. (180 сүз)

(Роза Хафизовадан)

**Очрашу**

Илдарны мәктәпкә очрашуга чакырдылар. Ул үзенең малай чагын исенә төшерде. Шәһәрнең хөрмәтле кешеләре алар классына да шулай килә торганнар иде. Җиденче класста укыган чакларында, алар генерал Булатов белән очраштылар. Класстагы малайлар аның күкрәгендәге орден белән медальләрен әллә ярты сәгать санадылар инде. Берлинны алган генерал аларга ул көнне бик күп гыйбрәтле вакыйгалар сөйләде.

Илдарлар ул көнне генералның сөйләгәннәрен авыз ачып тыңлап утырганнар иде. Ә ул үзе соң – биографиясен яза башласа, ярты биткә дә тутыра алмаган бер егет – балалар каршына барып ни сөйләр? Идел буе зонасында беренчелекне алу шаккатарлык эш түгел әле ул. Бу әле Илдарның үзе өчен дә зур спортка килүнең беренче адымнары гына. Киләчәктә, бәлки, ил буенча чемпион булыр әле ул, ә бәлки дөнья күләмендә дә. Тренеры аңа зур өмет баглый. Анысы әле киләчәк эше.

Берничә көн очрашу турында уйлап йөргәннән соң, ул аны Менжинский клубында уздырырга булды, укучыларны шунда чакырды.

Стенага эленгән портретлардан органнарда хезмәт итүче атаклы спортчылар карап тора. Араларында ил күләмендәге ярышларда катнашучылар да бар икән. Кайсы чаңгы буенча спорт мастеры, кайсылары – йөзү буенча. Шкафларда алар яулап алган кубоклар. Илдар Кәримов, аларның һәркайсы турында иркенләп сөйләде.

Соңыннан, кино залына кереп, “Беренче перчатка” дигән кино карадылар. (180 сүз)

(Л.Ихсанова буенча)